Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге составына керүче Тоба торак пунктында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2022 елның 2 декабре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлегенең Тоба торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районының Каенлы авыл җирлеге Тоба торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның ире/хатыннардан тыш; күрсәтелгән сумманың 50% күләмендә 2 группа инвалидлар һәм 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар түлиләр, 2023 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны су челтәрләрен алыштыруга (килешү буенча эшләр сатып алу, ташу, түләү, шул исәптән янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру) юнәлдерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Каенлы авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Гарипов